СОВЕТ БАВЛИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАУЛЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ КАРАР

08.04.2026 г.Бавлы 39

Баулы муниципаль район Советынын «Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районында муниципаль хезмәткәрне коррупциячел хокук бозулар кылуга этәрү максатларында мөрәҗәгать итү фактлары турында яллаучы (эш бирүче) вәкиленә хәбәр итү тәртибе хакындагы Нигезләмәне раслау турында» 2022 елнын 14 сентябрендәге 131 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясенең 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законының 9 статьясындагы 5 өлеше нигезендә, Баулы муниципаль район Советы **КАРАР ИТТЕ:**

1. Муниципаль хезмәткәрне Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районында коррупциячел хокук бозулар кылуга этәрү максатларында мөрәҗәгать итү фактлары турында яллаучы (эш бирүче) вәкиленә хәбәр итү тәртибе хакында Баулы муниципаль районы Советының 2022 елның 14 сентябрендәге 131 номерлы карары белән расланган Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

5 пунктны түбәндәге эчтәлектәге абзац белән тулыландырырга:

«Яллаучының (эш бирүченең) вәкиленә, прокуратура органнарына яки башка дәүләт органнарына аны коррупциячел хокук бозуга этәрү максатларында мөрәҗәгать итү фактлары турында, башка муниципаль хезмәткәрләрнең коррупциячел хокук бозулар кылу фактлары турында, белешмәләр тапшырмау, федераль законнарда билгеләнгән очраклардан тыш, белә торып тулы булмаган белешмәләр тапшыру йә белә торып тапшыру фактлары турында хәбәр иткән

муниципаль хезмәткәр керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында дөрес булмаган белешмәләр Россия Федерациясе законнары нигезендә дәүләт яклавында тора.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://www.pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы сайтында (http://www.bavly.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Баулы муниципаль районы Советының җирле үзидарә, законлылык, хокук тәртибе һәм депутат этикасы мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Баулы муниципаль районы Башлыгы,
район Советы рәисе И.И. Гозәеров